**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь, 2019 ел № 1793

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 971 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 971 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 2083 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең күрсәтелгән карар белән расланган хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

V кисәктеге 2 пунктның сигезенче абзацында «300» санын «550» санына алмаштырырга;

VI бүлегендәге 15 пунктта, 15.11 пунктының бишенче һәм җиденче абзацларында һәм «төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәнең V бүлегендәге 12.11 пунктының бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең күрсәтелгән карар белән расланган хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәнең 6 бүлегендәге 8 пунктындагы бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. С. Шәйхисламовка йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин